КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 апрель г.Казань № 409

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 июль, 524 нче; 2015 ел, 17 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 30 декабрь, 1140 нчы; 2020 ел, 15 июнь, 490 нчы; 2021 ел, 12 февраль, 73 нче; 2022 ел, 20 июнь, 591 нче; 2022 ел, 24 ноябрь, 1260 нчы; 2023 ел, 10 февраль, 127 нче; 2023 ел, 1 июнь, 667 нче; 2023 ел, 7 октябрь, 1260 нчы; 2024 ел, 16 декабрь, 1141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә оешмаларда, шул исәптән инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклауга бәйле чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктның икенче абзацында татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.6 пунктның беренче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.2 пунктның беренче абзацында татар текстында «Субсидия» сүзен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин